СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19;e-mail:Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение  Карар
№2-29  15 ноябрь 2023 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 03.03.2016 №1-7 карары белән расланган Ишки авыл җирлеге муниципаль хезмәтләре турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы №1-7 карары белән расланган Ишки авыл җирлеге муниципаль хезмәтләре турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында Совет карары проектын кабул итү турында Татарстан Республикасы Мамадыш районы прокуратурасы тарафыннан кертелгән модель акты проектын караганнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Ишки авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (18.11.2016 №2-14, 15.05.2017 №1-21, 28.07.2017 №3-22, 14.11.2017 №2-26, 05.06.2018 №2-32, 13.08.2018 №2-34, 20.11.2018 №3-37, 14.12.2018 №2-38, 21.03.2019 №1-40, 18.09.2019 №3-45, 19.02.2020 № 1-50, 17.11.2020 № 3-2, 10.06.2021 № 1-9, 08.10.2021 № 2-11, 22.06.2022 №2-16, 20.02.2023 №5-21, 13.06.2023 №2-23, 18.07.2023 №2-25) карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Пункты 9.5. 9.7 пунктларга «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.2. 11.7 пунктта «дөрес түгел яки» сүзләрен төшереп калдырырыга, «,федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.3. 23.3 пунктның 1 пунктына «яки «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге башлыгы Р.К.Хафизовка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы




/Р.К.Хафизов/